**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «Об утверждении Положения о порядке размещения сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, государственных гражданских служащих Республики Татарстан и членов их семей на официальных сайтах государственных органов Республики Татарстан и предоставления этих сведений средствам массовой информации для опубликования»**

В связи с изменениями в федеральном законодательстве по вопросам противодействия коррупции **постановляю**:

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 19 апреля 2010 года № УП-237 «Об утверждении Положения о порядке размещения сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, государственных гражданских служащих Республики Татарстан и членов их семей на официальных сайтах государственных органов Республики Татарстан и предоставления этих сведений средствам массовой информации для опубликования» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 1 ноября 2010 года № УП-711 и от 16 мая 2012 года № УП-343), в Положение о порядке размещения сведений о доходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, государственных гражданских служащих Республики Татарстан и членов их семей на официальных сайтах государственных органов Республики Татарстан и предоставления этих сведений средствам массовой информации для опубликования, утвержденное этим Указом, следующие изменения:

а) в Указе:

наименование и пункт 1 после слова «доходах» дополнить словом «, расходах»;

в преамбуле слова «статьи 8» заменить словами «статей 8 и $8^1$»;

б) в Положении:

наименование после слова «доходах» дополнить словом «, расходах»;

пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1. Настоящим Положением устанавливается порядок размещения сведений о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, государственных гражданских служащих Республики Татарстан, их супругов и несовершеннолетних детей (далее - сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера) на официальных сайтах государственных органов Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» (далее - официальные сайты), а также предоставления этих сведений общероссийским и республиканским средствам массовой информации (далее - средства массовой информации) для опубликования в связи с их запросами, если федеральными законами и законами Республики Татарстан не установлен иной порядок размещения указанных сведений и (или) их предоставления средствам массовой информации.»;

абзац первый пункта 2 после слова «доходах» дополнить словом «, расходах»;

пункт 2 дополнить подпунктом «г» следующего содержания:

«г) сведения об источниках получения средств, за счет которых совершена сделка по приобретению земельного участка, другого объекта недвижимого имущества, транспортного средства, ценных бумаг, акций (долей участия, паев в уставных (складочных) капиталах организаций), если сумма сделки превышает общий доход лица, замещающего государственную должность Республики Татарстан (государственного гражданского служащего Республики Татарстан), и его супруги (супруга) за три последних года, предшествующих совершению сделки.»;

абзац первый пункта 3 после слова «доходах» дополнить словом «, расходах»;

пункт 4 изложить в следующей редакции:

«4. Сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера, указанные в пункте 2 настоящего Положения, за весь период замещения лицом государственной должности Республики Татарстан (должности государственной гражданской службы Республики Татарстан), а также сведения о доходах, расходах, об имуществе и обязательствах имущественного характера его супруги (супруга) и несовершеннолетних детей находятся на официальном сайте того государственного органа Республики Татарстан, в котором замещается указанная должность, и ежегодно обновляются в течение 14 рабочих дней со дня истечения срока, установленного для их подачи.»;

абзац первый пункта 5 после слова «доходах» дополнить словом «, расходах»;

в подпункте «а» пункта 6 слова «в 3-дневный срок» заменить словами «в течение трех рабочих дней»;

в подпункте «б» пункта 6 слова «в 7-дневный срок» заменить словами «в течение семи рабочих дней»;

пункт 7 после слов «государственных органов Республики Татарстан» дополнить словами «, обеспечивающие размещение и представление средствам массовой информации сведений в соответствии с настоящим Положением,».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
14 августа 2013 года
№ УП-761

**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү турында**

Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча федераль законнардагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-237 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы һәм 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы Указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), әлеге Указ белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Указда:

атамасында һәм 1 пунктта «керемнәре» сүзеннән соң «,чыгымнары» сүзен өстәргә;

преамбулада «8 статьясын» сүзләрен «8 һәм $8^1$ статьяларын» сүзләренә алмаштырырга;

б) Нигезләмәдә:

атамасында «керемнәре» сүзеннән соң «,чыгымнары» сүзен өстәргә;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, аларның ирләренең, хатыннарының һәм балигъ булмаган балаларның керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне (алга таба – керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр) Татарстан Республикасы дәүләт органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында (алга таба – рәсми сайтларда) урнаштыру, шулай ук бу белешмәләрне, әгәр федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыруның һәм (яисә) аларны массакүләм мәгълүмат чараларына бирүнең башка тәртибе билгеләнмәсә, гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына (алга таба – массакүләм мәгълүмат чараларына) аларның сораулары белән бәйле рәвештә бастырып чыгару өчен бирү тәртибе билгеләнә.»;

2 пунктның беренче абзацында «керемнәре» сүзеннән соң «,чыгымнары» сүзен өстәргә;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле «г» пунктчасын өстәргә:

«г) әгәр килешү суммасы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның (Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең) һәм аның хатынының (иренең) килешүгә кадәрге соңгы өч елдагы кеременнән артык булса, җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (катнашу өлешләре, оешмаларның устав (кушылма) капиталларында пайлар) сатып алу буенча килешү башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.»;

3 пунктның беренче абзацында «керемнәре» сүзеннән соң «,чыгымнары» сүзен өстәргә;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр затның Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын (Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын) биләвенең бөтен чорына, шулай ук аның иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр күрсәтелгән вазыйфа биләнүче Татарстан Республикасы дәүләт органы рәсми сайтында була һәм аларны бирү өчен билгеләнгән вакыт тәмамлану көненнән соң 14 көн эчендә ел саен яңартыла.»;

5 пунктның беренче абзацында «керемнәре» сүзеннән соң «,чыгымнары» сүзен өстәргә;

6 пунктның «а» пунктчасында «3 көн эчендә» сүзләрен «өч эш көне дәвамында» дигән сүзләргә алмаштырырга;

6 пунктның «б» пунктчасында «7 көн эчендә» сүзләрен «җиде эш көне дәвамында» дигән сүзләргә алмаштырырга;

7 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт органнары» сүзләре алдыннан «әлеге Нигезләмә нигезендә урнаштыруны һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бирүне тәэмин итүче» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2013 ел, 14 август
№ ПУ-761